**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

__21.01.2025___ № ______4од_________

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2022 елның 20 сентябрендәге 152од номерлы боерыгы белән расланган Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2022 елның 20 сентябрендәге 152од номерлы боерыгы белән расланган Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2024 елның 13 февралендәге 23од номерлы һәм 2024 елның 25 ноябрендәге 210од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«Мөрәҗәгать итүчеләр исеменнән законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче затлар чыгыш ясарга мөмкин.»;

2.3 пунктның 2.3.1 пунктчасында:

икенче абзацта « мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (җибәрелгән)» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан КФҮ аша бирелгән очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен бирү факты «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында теркәлә.»;

2.6 пунктта:

2.6.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алу өчен мөстәкыйль рәвештә тапшыра торган кирәкле документлар исемлеге:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза):

билгеләнгән форма буенча кәгазь чыганактагы документ рәвешендә (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);

әлеге Регламентның 2.6.4 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон документ рәвешендә (гаризаның электрон рәвешенә тиешле белешмәләр кертү юлы белән тутырыла), Бердәм портал (техник мөмкинлеге булганда) яисә Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә;

б) нотариаль таныкланган күчермәләр булмаган очракта, мөрәҗәгать итүченең гамәлгә кую документларының төп нөсхәләре күрсәтелгән күчермәләре;

в) мөрәҗәгать итүченең вәкиленең шәхесен таныклаучы документ (Министрлыкка яки КФҮкә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта бирелә). Бердәм портал (техник мөмкинлеге булганда) яисә Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә шәхесне таныклаучы документтан белешмәләр электрон рәвештә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының үзара мәгълүмати-технологик эшчәнлеген тәэмин итә торган инфраструктурада (алга таба - ЕСИА) Бердәм идентификация һәм аутентификация системасындагы теркәлү язмасы расланганда тикшерелә;

г) дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүченең вәкиленең вәкаләтләрен таныклаучы документ.»;

2.6.5 пунктчасының икенче абзацында «, шулай ук мөрәҗәгать итүченең вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган белешмәләр (Федераль нотариаль палата, Нотариатның бердәм мәгълүмат системасы)» сүзләрен өстәргә;

2.14 пунктның 2.14.6 пунктчасында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«КФҮ кабул итүгә гариза бирүчеләрне язу (алга таба - язылу) Республика порталы аша, КФҮ бердәм белешмә хезмәте телефоны аша, КФҮ рәсми сайты (http://mfc.tatarstan.ru) аша башкарыла»;

унынчы абзацны төшереп калдырырга;

3.5 пунктның 3.5.2 пунктчасындагы өченче абзацында «(http://mfc16.tatarstan.ru) сүзләрен (http://mfc.tatarstan.ru)» сүзләренә алмаштырырга;

3.9 пунктның 3.9.2 пунктчасындагы икенче абзацында «3.9.1.» саннарын «3.9.2.1.» саннарына алмаштырырга;

күрсәтелгән регламентка 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Министр Р.И. Заһидуллин

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

(Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының ______________ _____ номерлы боерыгы редакциясендә)

Тәкъдим ителә торган форма

Татарстан Республикасы юстиция министрына
________________________________
(фамилия, исем, әтисенең исеме (булганда)
________________________________
________________________________ (оешма исеме, адрес (почта һәм (яки) электрон), телефон номеры (булганда)

ГАРИЗА

Сездән социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешма

________________________________________________________________
(социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешма исеме)

тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтнең

________________________________________________________________
(иҗтимагый файдалы хезмәт аталышы)

билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирүегезне үтенәм.

Оешманың чит дәүләт агенты функцияләрен башкаручы коммерцияле булмаган оешма түгеллеген, һәм бер ел һәм аннан артыграк вакыт дәвамында иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларын раслау турында» 2016 елның 27 октябрендәге 1096 номерлы карары белән расланган критерийларына туры килә торган санап кителгән иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүен раслыйбыз:

________________________________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәтнең Россия Федерациясенең норматив хокукый актларына туры килүе һәм аның эчтәлегенә таләпләр (күләме, сроклары, күрсәтү сыйфаты)

(иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүдә турыдан-туры җәлеп ителгән затларның (шул исәптән оешма хезмәткәрләренең һәм гражданлык-хокукый характердагы килешүләр нигезендә җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) тиешле квалификациягә (шул исәптән профессиональ белемгә, бу өлкәдә эш тәҗрибәсенә) ия булулары, мондый затларның тиешле күләмдә булулары)

(бәяләмә бирү елы алдыннан булган ике ел эчендә иҗтимагый файдалы хезмәтләр алучыларның аларны күрсәтү сыйфатыннан канәгать булулары (оешманың иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү белән бәйле гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, аларның компетенцияләре чикләрендә башка органнар тарафыннан нигезләнгән шикаятьләр булмау)

(коммерцияле булмаган оешма турындагы мәгълүматның ачыклыгы)

(бәяләмә бирү елы алдыннан булган ике ел эчендә оешманың «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән килешүләрне үтәү кысаларында хезмәт күрсәтүләр нәтиҗәләре буенча гадел булмаган тәэмин итүчеләр реестрында тормавын раслау)

Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен җибәрү ысулы:

☐ Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында тапшыру

☐ «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә һәм аның филиалларында тапшырырга («Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» һәм аның филиаллары аша гариза биргәндә)

☐ почта аша җибәрү

☐ электрон документ рәвешендә җибәрергә (гаризаны электрон почта аша, Бердәм дәүләт хезмәт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (функцияләр, Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы) аша җибәргәндә)

Раслаучы документлар өстәп бирелә:

1. ______________________
2. ______________________
3. ______________________

| вазыйфа | имза | фамилия, исем, әтисенең исеме (булганда) |
|---|---|---|

«___»____________20__ел.

М.У. (булганда)